| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.08.2018 г.Казань № 457

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 23 августында 4849 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге номерлы 883 карарын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең кушымтада бирелгән тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бүлекләре, аппарат секторлары җитәкчеләренә Тәртип таләпләре үтәлүен тәэмин итәргә

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.Ф.Вәлиуллловны җаваплы итеп билгеләргә.

**Министр в.б.** **Р.Ф.Вәлиуллов**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.08.2018 № 757 боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге номерлы 883 карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына аларга хокукый экспертиза уздырганда һәм аларның кулланылуын мониторинглаганда коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасын билгели.

2. Министрлыкның чыгарылган норматив хокукый актлары (алга таба – норматив хокукый актлар) һәм Министрлык аппаратының структур бүлекчәләре тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актларның проектлары (алга таба – норматив хокукый актларның проектлары) коррупциягә каршы экспертизага тиешле була.

3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актларның проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү тору.

Министрлыкта норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны оештыруда төп принциплар булып түбәндәгеләр тора:

1) норматив хокукый актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелүнең мәҗбүрилеге;

2) башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнештә норматив хокукый актны (норматив хокукый акт проектын) бәяләү;

3) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актларның проектларына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезле, объектив булуы һәм тикшерелеп торуы;

4) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актларның проектларына) коррупциягә каршы экспертиза уздыручы затларның компетентлылыгы;

5) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итүе.

4. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге номерлы 883 карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе, әлеге Тәртип нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән Методикага (алга таба – методика) туры китереп, Министрлыкның юридик бүлеге башлыгы яки Министрлыкның юридик бүлеге башлыгы булмый торган вакытта (командировка, отпуск, авыру һ.б.) аның урынбасары тарафыннан уздырыла.

5. Министрлык аппаратының норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсендә эшләнгән норматив хокукый акт проекты электрон документ әйләнеше системасы аша хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрелә.

6. Норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза, аларга хокукый экспертиза уздырылганда, Министрлыкның юридик бүлегенә электрон документ әйләнеше системасы буенча килгән көненнән башлап биш эш көненнән артмаган срокта гамәлгә ашырыла.

7. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проекты электрон документ әйләнеше системасы буенча Министрлыкның юридик бүлегенә килгән көннән башлап алты эш көне узганчы әлеге Тәртип кушымтасында бирелгән формага туры китереп бәяләмә төзелә, ул Министрлыкның юридик бүлеге башлыгы яисә, Министрлыкның юридик бүлеге башлыгы булмый торган вакытта (командировка, отпуск, авыру һ.б.), аның урынбасары тарафыннан имзалана.

Бәяләмәдә түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

- экспертизага тапшырылган норматив хокукый акт проектының реквизитлары;

- норматив хокукый акт проектында коррупциячел факторларның булуы яки юклыгы;

- норматив хокукый актның коррупциячел факторлары булган (коррупциячел факторлар ачыкланганда) конкрет нигезләмәләре;

- норматив хокукый акт проекты нигезләмәләренең тәгъбирләнешен үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен (коррупциячел факторлар ачыкланганда) аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

Министрлык аппаратының норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе, Министрлыкның юридик бүлегеннән коррупциягә каршы экспертизаны уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар күрсәтелгән бәяләмәне алганда, аларны норматив хокукый акт проектын өстәмә эшләп бетергәндә исәпкә ала һәм өстәмә эшләп бетерелгән норматив хокукый акт проектын яңадан карау өчен Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрә.

9. Министрлыкның норматив хокукый актларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен аталган документларны эшләүче норматив хокукый акт проектын тармак программаларын үстерү һәм эшләү бүлегенә җибәрә, анысы Министрлыкның юридик бүлегенә карау өчен җибәрелгән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Министрлыкның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында аларга карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актларның проектларын урнаштыру өчен булдырылган, аларга карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актларның проектларын урнаштыру өчен бердәм региональ интернет-портал буларак билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштыра. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен норматив хокукый актларның проектларын урнаштырганда аларны эшләүче бәйсез экспертиза уздыру, проект буенча тәкъдимнәр кертү сроклары турында мәгълүматны, шулай ук бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын, тапшырылган эксперт бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрне җыю, гомумиләштерү һәм исәпкә алу өчен, норматив хокукый актларның проектлары буенча эксперт бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрне җибәрү өчен аларның телефон, факс номерларын һәм электрон почта адресларын күрсәтеп, җаваплы белгечләрнең исемлеген күрсәтә.

Бу вакытта Министрлыкның норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы административ регламент проекты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – Министрлык сайты) урнаштырылган көннән башлап кимендә биш эш көне тәшкил итәргә тиеш, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларыннан тыш, алары өчен Министрлыкта административ регламент проекты урнаштырылган көннән башлап 15 эш көненнән азрак була алмый.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрне тәшкил итүче белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актларның проектларына карата үткәрелми.

Министрлыкның норматив хокукый актлары проектларын алар буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыру максатларында урнаштыру Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында эшләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары

турында иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм очракларда гамәлгә ашырыла.

10. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә норматив хокукый акт проектын эшләүче тарафыннан аны алган көннән башлап 15 көнлек срокта мәҗбүри каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре буенча бәйсез экспертизаны уздырган юридик яки физик затка нигезләнгән җавап җибәрелә, бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш.

Норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар Министрлык аппаратының норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе тарафыннан норматив хокукый акт проектын өстәмә эшләп бетерү стадиясендә бетерелә.

Эшләүче тарафыннан норматив хокукый акт проектына аңа коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырылганнан соң үзгәрешләр кертелгән очракта, норматив хокукый акт проекты яңадан коррупциягә каршы экспертизага тиешле була.

11. Министрлыкның норматив хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза аларның кулланылышын мониторинглаганда (алга таба – мониторинг) уздырыла.

Мониторинг Министрлыкның юридик бүлеге һәм Министрлык аппаратының норматив хокукый актларны эшләгән структур бүлекчәләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Министрлыкның структур бүлекчәләре норматив хокукый актка мониторинг уздырылган көннән башлап өч эш көне эчендә дәлилле нигезләп, норматив хокукый актны, әгәр үзләре эшләгән норматив хокукый актка мониторинг уздыру барышында хокук кулланучы зат өчен карар кабул итүнең нигезсез киңәйтелгән чикләрен яки гражданнарга һәм оешмаларга карата гомуми кагыйдәләрдән искәрмәләрне нигезсез куллану мөмкинлеген, билгеле булмаган, авыр үтәлә торган һәм (яки) мәшәкатьле таләпләрне билгеләү турында таныклаучы шартлар ачыкланса, коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрә.

Норматив хокукый актка коррупциягә каршы экспертиза ул электрон документ әйләнеше системасы аша Министрлыкның юридик бүлегенә килгән көннән башлап җиде эш көненнән артмаган срокта гамәлгә ашырыла, аның нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган тәртипкә аналогик рәвештә бәяләмә төзелә.

13. Министрлыкның юридик бүлеге бәяләмәсе нигезендә Министрлык аппаратының норматив хокукый актның кулланылышына мониторинг уздырган структур бүлекчәсе, Министрлыкның норматив хокукый актында ачыкланган

коррупциячел факторларны бетерү максатларында бәяләмәне алган көннән башлап исәпләнә торган җиде көнлек срокта әлеге Тәртип нигезендә тиешле норматив хокукый актка үзгәрешләр яки өстәмәләр кертү турында норматив хокукый акт проектын әзерли һәм Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрә.

14. Министрлык аппаратының норматив хокукый акт проектын әзерләү яки норматив хокукый актка мониторинг уздыру өчен җаваплы структур бүлекчәсе, Министрыкның норматив хокукый актларында һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актларның проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклаучы бәйсез (коррупциягә каршы бәйсез) экспертиза нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракта, законнарда билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән норматив хокукый актларның, норматив хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризалашмавын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрелүен тәэмин итә.

15. Норматив хокукый актка хокук куллануны мониторинглау кысаларында гамәлгә ашырылган коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юллана торган тиешле мәгълүмат составына кертелә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча

# БӘЯЛӘМӘ

______________________________________________________________
(норматив хокукый актнын/норматив хокукый акт проектының аталышы күрсәтелә)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге тарафыннан «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына, Россия Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру кагыйдәләренә һәм Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасына туры китереп, анда коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны юкка чыгару максатында,

______________________________________________________________карата
(норматив хокукый актнын/норматив хокукый акт проектының аталышы күрсәтелә)

экспертиза уздырылды.

1 нче вариант:

______________________________________________________________
(норматив хокукый актнын/норматив хокукый акт проектының аталышы күрсәтелә)

коррупциячел факторлар ачыкланмады.

2 нче вариант:

______________________________________________________________
(норматив хокукый актнын/норматив хокукый акт проектының аталышы күрсәтелә)

түбәндәге коррупциячел факторлар ачыкланды: ______________________________
______________________________________________________________.
(коррупциячел факторлары булган норматив хокукый актның конкрет нигезләмәләре күрсәтелә)

Ачыкланган коррупциячел факторларны юкка чыгару максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

______________________________________________________________
(коррупциячел факторларны юкка чыгару ысулы күрсәтелә: норматив хокукый акт проектының тәгъбирләнешен үзгәртү
______________________________________________________________
(аны башка редакциядә бәян итү, норматив хокукый акт проекты текстына бүтән үзгәрешләрне кертү,
______________________________________________________________.
аерым нигезләмәләрен төшереп калдыру яки башка төрле ысул)

«____»______ 20___ел.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | __________ | __________________ |
| (вазыйфа аталышы) | (имза) | (тулы имза) |